# Татарстан Республикасы
# Дәүләт Советы Президиумы

# КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханова грант нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча республика программасын әзерләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы мөрәҗәгате хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханова грант нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча республика программасын әзерләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы мөрәҗәгате текстын кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханова җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аппараты / Аппарат Государственного Совета Республики Татарстан
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Чистай шәһәре,
2013 елның 19 сентябре
№ 3048-IV ДС

2013 елның 19 сентябрендәге
3048-IV ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

Грант нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча республика программасын әзерләү турында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы мөрәҗәгате

Хөрмәтле Рөстәм Нургали улы!

Татарстан башкаласы Казан шәһәрен лаеклы рәвештә европа дәрәҗәсендәге шәһәр дип әйтергә мөмкин. XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерлек кысаларында да күп эшләр эшләнде: урамнар һәм яр буйларын төзекләндерү, инфраструктура үсеше, юллар, транспорт чишелешләрен төзү, шәһәрне яшелләндерү, ял һәм туристлык комплексларын булдыру. Казан яшәү өчен уңайлы шәһәргә әверелде, казанлыларның тормыш дәрәҗәсе һәм сыйфаты сизелерлек яхшырды.

Парламенттагы фракцияләрнең һәм депутат төркемнәренең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы адресына мөрәҗәгатендә чагылдырылган гомуми фикер буенча, әлеге эштә тукталып калмыйча, территорияләрне һәм башка муниципаль берәмлекләрне төзекләндерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Бу турыда хакимият институтларының, иҗтимагый берләшмәләрнең, оешмаларның уртак көчен таләп итүче күп кенә проблемаларның артуы турында Татарстан халкының күпсанлы мөрәҗәгатьләрендә дә чагыла.

Дәүләт-хосусый партнерлыкның заманча технологияләрен куллану мөмкинлеге булган грант программалары хәзерге вакытта граждан җәмгыятен формалаштыруга, халыкны социаль мәсьәләләрне чишүгә җәлеп итүнең нәтиҗәле инструменты булып тора.

Грант нигезендә программа кысаларында һәр торак пунктны территориаль төзекләндерү; суларның торышын һәм эчәр су белән тәэмин итүне (буа, күл һәм елга ярларын чистарту) яхшырту; җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү һәм урнаштыру, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, атмосфера һавасы торышын яхшырту, яшеллек утырту буенча санитар-савыктыру гамәлләре; балалар мәйданчыклары төзү, республиканың шәһәр, авыл торак пунктларында яшәүчеләрнең массакүләм яллары өчен шартлар тудыру һәм башка мәсьәләләр хәл ителер иде.

Депутатлар фикеренчә, мондый программа муниципаль берәмлек территорияләре торышын яхшырту, халыкның яшәү һәм тормыш сыйфатын яхшырту өчен кирәкле шартлар тудыру һәм республикадагы муниципаль берәмлекләрнең башка кичектергесез мәсьәләләрен хәл итү максатында гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең, оешмаларның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының үзара эшчәнлегенә юнәлдерелергә тиеш.

Рөстәм Нургали улы, “БЕРДӘМ РОССИЯ” Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге, республика парламентындагы депутат берләшмәләре инициативасы белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы грант нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча республика программасын әзерләү һәм кабул итү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә.